СОВЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Кооперативная, д. 22, с. Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

**Утар-Аты авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«29» сентябрь, 2017ел** **№ 40**

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Утар-Аты авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Утар Аты авыл җирлеге башкарма комитетының 22 санлы Карары нигезендә .№31» референдум үткәрү инициативасы турында", Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 сентябрендәге 39 номерлы «референдум үткәрү инициативасы турында» гы карары, Утар Аты авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Утар-Аты авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсәләсе буенча җирле референдум уздыруны 2017 елның 19 ноябренә билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

«2018 елда Утар-Аты авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә (түләү күләме 250 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 80 яштән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү гә җибәрү белән килешәсезме?

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Утар Аты авылы (9 Май урамы, Совет урамы, Комсомол урамы, Мәктәп урамы, Кооператив урамы), Субаш Аты авылы (Кооператив урамы, Яңа урамы, 9 Май урамы, Тарлау урамы), Орнашбаш авылы (Мичурин урамы, Зеленая урамы, Механизаторлар урамы, Тукай урамы, Клуб урамы, Яшьләр урамы, Комсомол урамы), Югары Аты авылы (Кооператив урамы, Комсомол урамы, Мәктәп урамы),

Иске Җөлбә авылы (Кооператив урамы, Комсомол урамы, Мәктәп урамы), Иске Җөлбә авылы (Мичурин урамы, Үзәк ур., 9 Май ур.), Кушлавыч авылы (8 Март ур.).

2. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Орнашбаш, Иске Җөлбә, Кушлавыч авылларында җәяүлеләр күперләрен ремонтлау.

3. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- материал алу, чишмә территориясен төзекләндерү;

Кушлавыч авылы;

- Орнашбаш авылында су башнясын сатып алу һәм урнаштыру.

4. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

-Утар Аты, Субаш Аты, Совет урамы, Комсомол урамы), Югары Аты, Субаш-Аты авылларында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру;

Орнашбаш, Кушлавыч, Иске Җөлбә авыллары.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

әйе юк

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга. http:pravo.tatarstan.ru) гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында мәгълүмат:

Утар Аты авылында (мәдәният йорты, китапханә бинасы, муниципаль берәмлекнең административ бинасы), Орнашбаш авылында (авыл клубы, китапханә бинасы); Кушлавыч авылында (китапханә, мәктәп бинасы).

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Утар-Аты авыл җирлеге башлыгы А.Г.Хәкимҗанов